| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**19.04.2021** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 842** |

Зеленодольск муниципаль районының «Айныткыч» муниципаль казна махсуслаштырылган учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында

Социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм «Айныткыч» муниципаль казна махсус учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәт хакын тәртипкә салу максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы карарына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Айныткыч» муниципаль казна махсус учреждениесенең Зеленодольск муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәт хакы айлык вазифаи окладтан, тиешле еллар эшләгән өчен вазифаи окладка айлык өстәмә түләүдән, катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен вазифаи окладка айлык өстәмә түләүдән, эш нәтиҗәләре буенча премияләрдән, матди ярдәмнән, шулай ук законнар нигезендә башка түләүләрдән тора дип билгеләргә. Белгечләрнең хезмәт хакы составына шулай ук һөнәрләрне берләштергән өчен өстәмә түләүләр, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйтү һәм үзләренең төп эше белән беррәттән вакытлыча булмаган хезмәткәрләрнең бурычларын үтәү һәм хезмәт шартларын махсус бәяләү буенча айлык компенсация түләүләре дә кертелә.
2. Кушымта нигезендә «Айныткыч» муниципаль казна махсус учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазифаи окладлары күләмнәрен расларга.
3. Оешма җитәкчеләренә һәм белгечләренә түбәндәгеләрне билгеләргә

а) тиешле еллар эшләгән өчен вазифаи окладка түбәндәге күләмнәрдә айлык өстәмә түләү:

| | |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр эш стажы булганда | процент |

| | |
|---|---|
| 5 елдан алып 10 елга кадәр | 7 |
| 10 елдан алып 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан артык | 15; |

б) вазифаи окладның 10 проценты күләмендә эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге (эшчәнлек спецификасы) өчен вазифаии окладка айлык өстәмә түләү;

в) хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә эш нәтиҗәләре буенча премияләр (премия күләме хезмәткәр эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләм белән чикләнми);

д) матди ярдәм-хезмәткә түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә;

4. Түбәндәге өстәмә түләүләр билгеләргә:

а) һөнәрләрне бергә алып барган, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйткән һәм эш урынында вакытлыча булмаган хезмәткәрләрнең вазифаларын үзенең төп эше белән беррәттән вакытлыча башкарган өчен, билгеләнгән хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә, төп эш буенча вазифаи окладының 50 процентына кадәр күләмендә өстәмә түләүләр.

б) төнлә эшләгән өчен белгечләргә (22 сәгатьтән 6 сәгатькә кадәр) вазифаи окладның 35 проценты күләмендә;

в) бәйрәм көннәрендә эшләгән өчен-көнлек тариф ставкасының икеләтә күләмендә;

г) хезмәт шартларын махсус бәяләү буенча белгечләргә вазифаи окладның 10 проценты күләмендә айлык өстәмә түләү;

5. Хезмәткәрләргә бирелгән субвенцияләр кысаларында, тиешле федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларда каралган башка түләүләрне бирергә.

6. Учреждение җитәкчеләренә һәм белгечләренә хезмәт өчен түләү фондын формалаштырганда вазифаи окладларны түләү өчен җибәрелә торган акчаларның суммасыннан тыш (компенсация түләүләрен исәпкә алып), түләүгә (бер елга исәпләгәндә) түбәндәге акчалар каралган: тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә түләү - вазифаи окладларның 5 проценты күләмендә;

җитәкчеләр һәм белгечләрнең махсус эш режимы, эшенең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен айлык вазифаи окладка өстәмә түләү-вазифаии окладларның 10 проценты күләмендә;

төнлә эшләгән өчен белгечләргә вазифаи окладның 35 проценты күләмендә;

хезмәт шартларын махсус бәяләү буенча белгечләргә айлык өстәмә түләү вазифаи окладларның 10 проценты күләмендә.

7. «Айныткыч» муниципаль казна махсус учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазифаии окладлары, шулай ук аерым оешмалар хезмәткәрләренә айлык һәм башка түләүләр күләме арттыру ягына тулы бер сумга кадәр түгәрәкләнергә, дип билгеләргә;

оешма җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазифаи окладларын арттыру, җәмәгать урыннарында исерек хәлдә булган затларга махсуслаштырылган учреждениеләрдә хезмәт күрсәтү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бирелгән субвенцияләр кысаларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары буенча гамәлгә ашырыла;

әлеге карар кабул ителгәнлектән, учреждение хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүнең башка шартлары кулланылмый.

8. «Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МУ, әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны, билгеләнгән тәртиптә, финанслауны тәэмин итәргә.

9. 4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 нчеапреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

10. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Р.Ганиев

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына кушымта
19.04.2021ел, №842

Зеленодольск муниципаль районының
«Айныткыч» муниципаль казна махсуслаштырылган учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазифаи окладлары күләме

| Вазифа атамасы | Вазифаи окладларның күләме, сумнарда |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Начальник | 23700 |
| Начальник урынбасары | 21300 |
| Баш белгеч | 12900 |
| Әйдәп баручы белгеч | 11700 |